Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 август 2019 ел №317

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2019 елның 9 августындагы 14394 санлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына тәкъдим ителгән үзгәрешләр проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составын расларга.

3. 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга.

4. «Әлмәт таңнары» һәм «Альметьевский вестник» газеталарында бастырып чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын;

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне әзерләү буенча комиссия составын;

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен;

- 4 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында халык тыңлаулары үткәрү тәртибен.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча халык тыңлауларын 2019 елның 8 ноябрендә 15.30 сәгатьтә Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының зур утырышлар залында үткәрүне билгеләргә (Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт, 325 нче бүлмә) .

Әлмәт муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында халык тыңлауларын уздыру турында яңа укылыштагы Нигезләмә нигезендә комиссиягә Уставка үзгәрешләр проектын тикшерүне һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутатлык этикасы мәсьәләләре һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2019 елның
28 августындагы 317 санлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты

1. 6 нчы маддәнең 1 нче өлеше 13 нче пунктын «, җирлекара территориядә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү;» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2. 6.1 маддәсенең 1 нче өлешен:

2.1. түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1) җылылык белән тәэмин итүнең бәяле зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәк булган һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы Федераль закон нигезендә билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә аның өчен билгеләнгән чараларның үтәлүенә муниципаль контрольне тормышка ашыру;»;

2.2. 12 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

12) авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, территорияне планлаштыру буенча авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән документацияне раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәт (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнарда күздә тотылган очраклардан кала), авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү вакытында объектларны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше буенча проектлауның җирле нормативларын раслау, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервка кую һәм җир участокларын тартып алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күздә тотылган очракларда биналарны, корылмаларны тикшерү һәм шундый тикшерү барышында ачыкланган хилафлыкларны бетерү турында рекомендацияләр бирү, планлаштырылган индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турындагы уведомлениедә (алга таба – планлаштырылган төзелеш турындагы уведомление) күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру параметрларына туры килүе һәм рөхсәт бирелүе турында уведомление, планлаштырылган индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турындагы уведомлениедә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының җир участогында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру параметрларына туры килмәве һәм рөхсәт бирелмәве турында уведомление, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир участокларында индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзегән яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында уведомлениеләр юллау,

максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаучы яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланылучы җир участогын тартып алу турында карар кабул итү, үз белдеклегең белән төзелгән корылманы сүтү яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күздә тотылган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерүне тормышка ашыру, җирлекара территориядә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү;

3. 26 нчы маддәдә:

3.1.7 нче өлешне түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«7. Район Советы депутаты, җирле үзидарә сайланулы вазифаи заты 25.12.2008 елгы 273-ФЗ санлы "Коррупциягә каршы тору турында"гы Федераль закон, 03.12.2012 елгы 230-ФЗ санлы "Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка кешеләрнең чыгымнары белән керемнәре тәңгәл килүенә контроль турында"гы Федераль закон, 07.05.2013 елгы 79-ФЗ санлы "Аерым категория кешеләргә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булуны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрен саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында"гы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны сакларга, вазифаларын үтәргә тиеш.»;

3.2. 9 нчы өлешне "җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи заты" дигән сүзләрдән соң "яки әлеге кешеләргә карата башка җаваплылык чаралары куллану" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3.3. түбәндәге эчтәлектәге 9.1 өлеше белән тулыландырырга:

«9.1. Үзенең керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирмәгән депутатка, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затына карата, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла ала:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасын район Советындагы, җирле үзидарә сайланулы органындагы вазифасыннан азат итү һәм вәкаләтләре срогы беткәнчегә кадәр район Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифа биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне башкарудан азат итеп, вәкаләтләре срогы беткәнче даими нигездә вәкаләтләрне башкару хокукыннан мәхрүм итү;

4) вәкаләтләре срогы беткәнче район Советында, җирле үзидарә сайланулы органында вазифа биләүне тыю;

5) вәкаләтләре срогы беткәнче даими нигездә вәкаләтләрне башкаруны тыю.»;

3.4. түбәндәге эчтәлектәге 9.2 өлеше белән тулыландырырга:

«9.2. Депутатка, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затына карата әлеге маддәнең 7.3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

3.5. 35 нче маддәнең 6 нчы өлешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«6. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгәндә район Советы депутаты, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затының вәкаләтләре срогыннан алда туктатыла.

06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон белән башка

очраклар күздә тотылмаганда, 25.12.2008 елгы 273-ФЗ санлы "Коррупциягә каршы тору турында"гы Федераль закон, 03.12.2012 елгы 230-ФЗ санлы "Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка кешеләрнең чыгымнары белән керемнәре тәңгәл килүенә контроль турында"гы Федераль закон, 07.05.2013 елгы 79-ФЗ санлы "Аерым категория кешеләргә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булуны, кулдагы акча средстволарын һәм кыйммәтләрен саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында"гы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны сакламаган, вазифаларын үтәмәгән очракта депутат, җирле үзидарә сайланулы вазифаи затының вәкаләтләре срогыннан алда туктатыла.»;

4. 42 нче маддәнең 3 нче өлешендә икенче җөмләне алып ташларга;

5. 44 нче маддәдә:

5.1. 1 нче өлештә:

5.1.1. 3 нче пунктның унөченче абзацын «, җирлекара территориядә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирә;» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

5.1.2. 1 нче өлешнең 5 нче пунктындагы 8 нче абзацны үз көчен югалткан дип санарга;

5.2. 2 нче өлештә:

5.2.1. 1 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«1) халыкка торак-коммуналь, транспорт, көнкүреш һәм башка хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә:

- авыл җирлекләре чикләрендә законнарда күздә тотылган тәртиптә электр, җылылык, газ белән тәэмин итүне оештыра;

- җылылык белән тәэмин итүнең бәяле зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәк булган һәм җылылык белән тәэмин итү схемасында «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы Федераль закон нигезендә билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә аның өчен билгеләнгән чараларның үтәлүенә муниципаль контрольне тормышка ашыра;

- авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм, парковкалар (туктау урыннары) булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне тормышка ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген тормышка ашыру һәм автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә башка вәкаләтләрне башкару;

- халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыра һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруны тәэмин итә;

- авыл җирлекләрендә яшәүче һәм торакка мохтаҗ булган аз тәэмин ителешле гражданнарны торак белән тәэмин итә, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыра, торак төзү өчен шартлар тудыра, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен тормышка ашыра;

- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне, авыл җирлекләре китапханәләренең китапханә фондын комплектлауны һәм аның сакланышын тәэмин итүне оештыра;

- җирле традицион халык иҗатын үстерү өчен шартлар тудыра, авыл җирлекләрендә халык һөнәрчелеген саклап калу, торгызу һәм үстерүдә катнаша;»;

5.2.2. 3 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«- җирлек чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирә, төзелешкә рөхсәт бирә, төзү, реконструкцияләүне тормышка ашырганда авыл җирлекләре территориясендә урнашкан объектларны, капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирә;»;

5.2.3. 44 нче маддәнең 2 нче өлеше 3 нче пунктындагы унберенче абзацта “Россия Федерациясе граждannар законнары нигезендә үз белдеклегең белән төзегән корылманы сүтү турында карар, үз белдеклегең белән төзегән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары, җирдән файдалану яки төзелеш алып баруның билгеләнгән кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документация яки капиталь төзелеш объектларына карата федераль законнар белән билгеләнгән параметрларга карата мәҗбүри таләпләр белән туры китерү (алга таба - билгеләнгән таләпләр белән туры китерү)» дигән сүзләрне алып ташларга;

6. 87 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 5 нче өлеш белән тулыландырырга:

«5. Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә район бюджетына башка муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан субсидияләр бирелә ала.»;

7. 88 нче маддәнең 1 нче өлеше беренче абзацында «Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджет хокукый мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлар» дигән сүзләрне «бюджет хокукый мөнәсәбәтләрен җайга салучы хокукый актлар, ачык норматив йөкләмәләрне һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләрне китереп чыгаручы хокукый актлар нигезләмәләре, шулай ук бюджеттан средстволар бирү турындагы дәүләт (муниципаль) контрактлары, килешүләр (килешенүләр) шартларын үтәү» дигән сүзләр белән алыштырырга.

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2019 елның
28 августындагы 317 санлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссия СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Зимин А.А. | Әлмәт муниципаль районы шәһәре башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| 2. | Баһманов И.Р. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе вәкиле, законлылык, хокук тәртибе, депутатлык этикасы мәсьәләләре һәм җирле үзидарә буенча даими комиссия рәисе |
| 3. | Закиров Ш.К. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Югары Мактама авыл җирлеге вәкиле, икътисади үсеш, ТКХ һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 4. | Парфилова Н.В. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Әлмәт шәһәре вәкиле |
| 5. | Михайлов В.Н. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе башлыгы |
| 6. | Әфләтунова Р.Е. | Әлмәт муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе |
| 7. | Ханнанова Ә.Б. | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хокук идарәсе начальнигы |

Муниципаль район
башлыгы урынбасары — А.А. Зимин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2019 елның
28 августындагы 317 санлы
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. Әлеге тәртип 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә катнашуын һәм аларның тәкъдимнәрен исәпкә алуны билгели.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча тәкъдимнәр Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча Әлмәт муниципаль районы Советына язма рәвештә, кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кертелә:

| № п/п | Пункт, подпункт | Проект тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмә исәпкә алынган проект тексты | Нигезләмә | Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны, имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 дән 17 сәгатькә кадәр Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты «Әлмәт таңнары» һәм «Альметьевский вестник» газеталарында басылган көннән соң 20 көн дәвамында кабул ителә.

3. Халык тыңлауларында катнашу өчен заявкалар шәхсән яки почта аша (конвертка «Уставны тикшерү» дип языла) Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча, шулай ук 39-01-31 факсы буенча, халык тыңлауларын үткәрү көненә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре һәм чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашуга заявкалары Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хатлар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм тикшерү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссиягә тапшырыла.

5. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектында булган үзгәрешләргә карата гына кертелә һәм федераль законнар таләпләренә туры килергә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының башка нигезләмәләренә каршы килмәскә яисә алар белән килешмәвенә юл куелмаска һәм район Уставы нигезләмәләренең бер мәгънәдә генә аңлатылуын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге тәртиптә күздә тотылган тәртипне, форманы һәм срокларны бозып кертелгән тәкъдимнәр комиссия карары буенча тикшерелмичә калдырылырга да мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты, шулай ук гражданнарның халык тыңлауларына чыгарылган тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында халык тыңлауларын уздыру турында яңа укылыштагы Нигезләмә нигезендә халык тыңлауларында тикшерүгә

чыгарыла.

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2019 елның
28 августындагы 317 санлы
карарына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында халык тыңлауларын үткәрү тәртибе

1. Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча халык тыңлаулары 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 28 нче маддәсе, Әлмәт муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында халык тыңлауларын үткәрү турында яңа укылыштагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

2. Район Уставы проекты һәм район Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты аны кабул итү турындагы мәсьәлә район Советы тарафыннан каралачак көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Бер үк вакытта әлеге проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча халык тыңлауларын билгеләү турында район Советы карары да бастырып чыгарыла.

Район Уставын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында аңа Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлаучы үзгәрешләр кертелгән очракта район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару таләп ителми.

3. Район Уставын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында аңа Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгән очраклардан кала, район Уставы проекты буенча яки район Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча халык тыңлаулары район Уставында билгеләнгән срокларда үткәрелә.

4. Халык тыңлауларын үткәрү турында карар басылып чыккан көннән алып аларны үткәрү көненә кадәр районда яшәүчеләр халык тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәрен, искәрмәләрен һәм төзәтмәләрен җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән тәкъдимнәр, искәрмәләр һәм төзәтмәләр халык тыңлауларында катнашучылар игътибарына җиткерелә.

5. Устав проекты яки район Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча халык тыңлаулары үткәрү буенча вәкаләтле орган булып комиссия тора.

6. Халык тыңлауларында район башлыгы, район башлыгы урынбасары, район Советының даими комиссияләре рәисләре рәислек итә ала. Рәислек итүче халык тыңлауларын ача, халык тыңлаулары соравын (сорауларын), тыңлаулар үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, тыңлауларны үткәрү инициаторларын күрсәтә.

7. Рәислек итүче халык тыңлауларын үткәрү инициаторлары тарафыннан вәкаләтле итеп сайланган затка, шулай ук халык тыңлауларында чыгыш ясарга хокукы булган катнашучыларга сүз бирә. Чыгышларның чират тәртибе комиссия тарафыннан теркәлгән гаризалар чираты буенча билгеләнә.

8. Тыңлауларда катнашучылар халык тыңлауларында башка катнашучылар

тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәргә кушылырга һәм (яки) үз рекомендацияләрен кире алырга хокуклы.

9. Халык тыңлаулары вакытында беркетмә алып барыла. Халык тыңлауларында катнашучыларның тыңлаулар барышында керткән барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре халык тыңлаулары секретарена юллана.

10. Беркетмә халык тыңлауларында рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм район Советында саклана.

11. Халык тыңлаулары беркетмәсе нигезендә, халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 3 эш көне эчендә, халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында заключение төзелә.

12. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм халык тыңлаулары уздырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин